Татарстан яшьләре

№13

(8891)

ШИМБӘ

29 гыйнвар. 1994 ел

Бәясе килешү буенча.

* ЯШЬЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ * 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА *



"Канатлы барс" - канатлы сүз осталарына

(Конкурс нәтиҗәләре)

Татарстанның Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан үткән ел башында игълан ителгән "Канатлы барс" конкурсының нәтиҗәсе билгеле булды. Бәйгедә катнашкан журналистлар һәм язучыларның Татарстан Республикасын мөстәкыйль, хокукый дәүләт итеп таныту максатыннан чыгыш басылган язмалары түбәндәгечә бәяләнде.

Жюри беренче урынга чыгарлык язма булмады дигән карарга килде.

Икенче урын (500 әр мең сум) ике язучы-журналистка - Марсель Галиев белән Рашат Низамиевка бирелә.

Өченче урын өчен тиешле дүрт бүләк (250 шәр мең сум) журналистлар Владимир Белосков, Марсель Зарипов, Мидхәт Миншин һәм Венера Якуповага тапшырыла.

Бер төркем авторларга (Алмаз Алеев, Рәшит Әхмәтҗанов, Флүс Латифи, Илдар Низамов) кызыксындыру призлары (диктофоннар) бүләк ителә. Алар арасында безнең даими авторыбыз, язучы Мөхәммәт ага Мәһдиев тә бар. Шулай ук укучыларыбызга сәяси темага язылган мәкаләләре белән яхшы таныш булган Талгать Бариевның язмалары да махсус бүләккә лаек дип табылды.

Газета ярдәм итте

Казахстанның Семипалат шәһәрендә яшәүче милләттәшләребез гореф-гадәтләребезне, телебезне саклау юнәлешендә нәтиҗәле эш алып баралар.

Сабыйларны укыту өчен дәреслекләр кирәк булгач, өлкәнең татар иҗтимагый үзәге "Татарстан яшьләре" аша Татарстандагы мәктәпләргә мөрәҗәгать иткән иде. Ярдәм озак көттермәде. Яңалары да, файдалануда булганнары да килде дәреслекләрнең. "Мең рәхмәт милләттәшләребезгә һәм "Татарстан яшьләре"нә", - ди бирәдәге татар иҗтимагый үзәге активисты Наилә ханым Абделкәримова.

"Татар-Информ"



Инде хәбәр иткәнебезчә, "Кырмыска" смотр-конкурсында җиңүче дип табылган Кукмараның 4 нче урта мәктәбенә "КАВЗ" маркалы автобус бүләк ителгән иде. Шушы көннәрдә башкалабыз урамнарында "Татарстан яшьләре" газетасы һәм ул үткәргән конкурс эмблемалары белән бизәлгән автобус пәйда булды. "Укучыларыбыз бик шатланды, - ди мәктәп директоры Рафаэль Мостафин, - хәзер һәр сыйныфта автобус белән кая сәфәр тотачаклары турында кайнар бәхәсләр бара".

Рәсемдә: менә ул җиңүчеләргә бирелгән бүләк.

Евгений КАНАЕВ фотосы.



Килешкәннәр

Мадридта Испаниянең һәм Татарстанның сәүдә-промышленность палаталары арасында хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куелган. Бу турыда Мадридтан Татарстан Президентының Матбугат үзәге хәбәр итте. Аннан күренгәнчә, безнең делегацияне бик җылы кабул иткәннәр, ике ил эшмәкәрләренең хезмәттәшлеген нәтиҗәле итү чаралары турында тәфсилле сөйләшүләр булган. М.Шәймиев һәм делегация вәкилләре 150 ил катнашында үткәрелүче туризм буенча Халыкара ярминкәдә катнашканнар, Испаниянең сәүдә һәм туризм министры белән очрашканнар.

Кәҗә - мал, сәпит - транспорт

Моңарчы санга сугылмаган велосипед һәм мопедлар да бүгеннән соң транспорт төренә кертеләчәк. Шуңа да ата-аналарга яше 12 гә җитмәгән балаларына сәпит алып бирергә ашыкмаска киңәш итәбез. Чөнки бу төр транспортта йөрү хокукы нәкъ менә шул яшькә җиткәннәргә генә биреләчәк. Моның өчен махсус курсларда укырга, дәүләт номеры алырга һәм, билгеле инде, күпмедер күләмдә акча да түләргә туры киләчәк. Ә мопед йөртү хокукы 14 яшькә җиткәннәргә генә бирелә. Кызыксынучылар өчен бер генә сан китерәбез - бүген Казан кибетләрендә сәпитләр 50-62 мең сум тора.

"Дүрт татар" җиңеп кайткан

Одессага КВНчылар ярышына киткән казанлылар җиңү белән кайттылар. Без аларны озакламый "Останкино"дан баручы шаяннар һәм тапкырлар тапшыруында күрә алачакбыз. Команда составында 10 студент катнашса да, ул "Дүрт татар" дип атала. Илдар Фәтхетдинов җитәкчелегендәге КВНчыларның символы - Татарстан символы. Сүз уңаеннан, безнең барс алып баручы А.Масляковның хатынына гына түгел, ә бәйгедә катнашкан 36 команда вәкилләренә дә бик ошаган.

Арзанлы ипи утравы

Татарстан үзе белән чиктәш Русия өлкәләрен һәм республикаларның халкын ипигә туендыруын дәвам итә. Капчыклап ипи төялгән электричкалар һәм дизель поездлары көн саен Казаннан, Арчадан, Әгерҗедән һәм тагын башка чиктәш шәһәр һәм район үзәкләреннән тонналап ипи ташый. Шушы көннәрдә генә (20 гыйнвардан) кан кардәшләребез булган Башкортостанда да ипи һәм сөт бәяләре күтәрелде. Арыш икмәгенең буханкасы хәзер Уфада - 160 сум, бодай икмәгә 240-280 сум тора. Димәк, озакламый арзанлы ипи утравы булган Татарстан да бәяләрне үзгәртәчәк.

Күңелле хәбәр

Пенсионерларның айлык керемнәре 1 февральдән 8 мең сумга арта. Татарстанның Халыкны социаль тәэмин итү министрлыгы хәбәр итүенә караганда, моңарчы үз пенсияләренә 11700 сум өстәмә алучылар өчен февральдән бу сумма 19700 сум итеп үзгәртелә.

Санаулы көн калды



"Болгар фонды" лотереясының тиражы 1994 елның 15 февралендә телевидениедә туры эфир буенча 20 сәгатьтә уйнатылачак.

Отышларны мәктәпкәчә яшьтәге балалар 7 барабан әйләндереп билгели.

"Болгар фонды" лотереясы

ул:

- 400 млн. сумлык отышлар!

- Бары 500 сумга фатир, автомобиль, туристлык путевкасы һ.б!

- Санаулы көн эчендә миллионер булу мөмкинлеге!

Уңышка ирешү мөмкинлеге дә көн саен артып тора:

- предприятиеләр һәм эре эшкуарлар үзләренең исемле призларын булдыруны дәвам итәләр, бүләк фондындагы 10 автомобильгә инде тагын 3 автомобиль, затлы тун, зур акча отышлары һ.б. өстәлде.

Ашыгыгыз - безнең лотереяда бөтен кеше дә ота!

Билетны бүген сатып алыгыз, иртәгә соң булачак!

Телефоннар: 32-19-78, 36-74-73.

Оештыру комитеты.

Вил Мирзаянов тагын кулга алынган

18 февраль көнне аптекага даруга чыккан җиреннән химия фәннәре докторы Вил Мирзаяновны кулга алганнар. Мөгаен, галим өчен бу артык көтелмәгән хәл булмагандыр. Эш шунда, суд яшерен актларны теркәүдән, шаһитларны чакырудан баш тартканлыктан һәм гамәлдәге Конституциянең бөтен нормаларын бозганлыктан, галим Мәскәү судына бүтән бармаска һәм сорауларга җавап бирмәскә карар иткән.

Русиядә яшерен рәвештә яңа бинар химик корал эшләнүе һәм сыналуы турында бөтен дөньяны кисәткән галимне Мәскәү судьялары дәүләт серен ачуда гаепләмәкче булалар. Вил Мирзаянов үзен гаепле дип санамый, чөнки ул "бинарның" формуласын да, аңа керүче конкрет матдәләрне дә атамаган.

Галимне болай эзәрлекләү халыкара килешүләргә бәйле рәвештә химия коралыннан баш тартырга тиешле Русия хәрби промышленность комплексының икейөзле сәясәтенә бәйле.

Низаг дәвам итә

Кемне яклаганыңны әйтсәң - үзеңнең кемлегеңне әйтәм

Яшьләр үзәге тирәсендә шаушуга тынарга ирек бирмиләр. Бүген төрледән-төрле сәяси һәм иҗтимагый оешмалар, хәрәкәтләр форсаттан файдаланып калу ягын карый. Моңарчы күзгә-башка ташланмаган "Граждане РФ", "Согласие", ДПР кебек хәрәкәтләрнең җитәкчеләре Татарстан прокурорына хөкүмәтнең карарын кире кагарга чакырып мөрәҗәгать белән чыктылар. Ә прокурор исә Министрлар Кабинетының Яшьләр үзәген "Ак барс" акционерлык банкына бирү турындагы карарын бары тик Конституцион күзәтчелек комитеты яки Президент М.Шәймиев үзе генә үзгәртә ала дип белдерде.

Әлеге уңайдан күпмилләтле "Суверенитет" хәрәкәте дә белдерү белән чыкты. Анда Татарстанны Русия составында күрергә теләүче газеталарның "Ак барс" банкына юнәлдерелгән провокацион чыгышлары чынлыкта республиканың мөстәкыйльлегенә каршы алып барыла торган көрәш дип бәяләнә.

М.ФӘТТАХЕТДИНОВ.

Укыдыгызмы, ишеттегезме...

1993 елның беренче кварталында Русиядә төрле инфекция һәм паразитар чирләрдән үлүче сабыйлар саны 33,3 процентка арткан. Бер яшькә кадәрге авыру балаларның 85 проценты үлә. Гомумән, Русиядә гомуми үлем дәрәҗәсе мең кешегә 12,2гә арткан. Гомер озынлыгының уртача дәвамлылыгы 68,7 яшькә кадәр төшкән.

* * *

Русия президентының амнистия турындагы указы җәмгыятьтә төрле карашлар тудырды. Берәүләр моны гуманлык акты дип якласа, икенче берәүләр болай да җинаятьчелек котырып чәчәк аткан чорда төрмә ишекләрен ачу хәлне тагын да катлауландырмагае дип курка.

* * *

"Смирнофф" аракысы төягән йөк машинасы серле рәвештә Мәскәү уртасында юкка чыга. Бу йөкне 90 мең доллар түләп "Парадис лтд" фирмасы сатып алган була. Берничә көннән юл кырында йөкне озата баручы экспедиторның башы ярылган үле гәүдәсе табыла, ә машина белән шоферның әлегә эзе дә юк.

* * *

Одесса өлкәсендә холера чире кабынган. Арциз район үзәк хастаханәсенә генә дә 12 авыру китерелгән.

* * *

Русия башкаласында 1 гыйнвардан телефон бәяләре артты. Хәзер өйдәге бер аппарат өчен ай саен 900 сум, блокировкалы өчен - 540, параллель телефон өчен 160 сум түләргә кирәк. Телефон кертүнең бәясе - 90 мең сум.

* * *

"Саратовобувь" акционерлык берләшмәсендә чыккан янгынны сүндерү өчен сигез сәгать вакыт кирәк булган. Янгын вакытында өч кеше үлгән. Матди зыян 40 миллион белән исәпләнә. Псков шәһәрендә торак йортта чыккан янгында да өч кеше тере килеш янып үлгән.

* * *

Халыкара француз радиосының белдерүенә караганда, АКШның Русиягә карашы бик беркатлы. Америка администрациясе Русиянең элекке совет империясен торгызырга җан-фәрман тырышуын күрми. Русия бу максатын тормышка ашыру өчен БДБ илләренең милли акчаларын тотрыксызландырып, үзенең "рубль" зонасына тартып кертү өчен бөтенесен дә эшли.

АЛЛАКЧЫЛЫККА ТАБЫНУЧЫЛАР

Миргазиян ЮНЫС

(Ахыры. Башы газетаның 12 нче санында).

Вил шика баш күтәрүенең тарихын сөйли. Туксаныщар минутлык ике кассетаны мин күз карасы шикелле саклап тотам. Ул кассеталарга язылган сүзләрдә империянең милитар вәхшилеге, җир шарына туфан булып җәелгән кан коюлар һәм киләчәктә коелачак каннар - боларның барысы да язылган. Ә без, язучылар, әч пошырып, "батырлар" турында язып, гомер уздырдык. Ак кәгазьләребезне эшелонлап исраф иттек. Татар кешесе, чыннан да, сугышта батыр булды. Ачыклыйк: бу батырлык татар халкына нәрсә бирә алды? Империя кулындагы камчыны юанайтудан, безнең богауларыбызны ныгытудан башка берниндә уңай нәрсә эшли алмады. Сугышта күрсәткән батырлык, әгәр аны фәлсәфи яктан бәяләсәң, көтүдәге сарык күрсәткән харизмат кыюлык кына булып кала килде. Безнең татарда гражданлык батырлыгы юкка чыгарылган. Бу сыйфатны инде күптән "Кызыл кенәгә"гә теркәргә кирәк иде. Менә шушы юнәлештән караганда Вил Мирзаянов күрсәткән батырлык, минемчә, татар тарихында римлеләрнең Муций Сцеволла батырлыгына тиң булып язылып калырга тиеш. Хәтерли торгансыздыр, Рим каласын карфагенлылар чолгап алганнар. Калада ачлык, тиф авыруы һәм кара тешенкелек. Күз алдына 1552 елның октябре. Явыз Иван гаскәрләре чолгап алган Казан килеп баса. Карфагенлылар разведкага чыккан рим солдатларын әсир итеп алалар һәм шул чакта аларга аңлаталар: "Нигә интегәсез, сезнең рухыгыз сынган, каршылык күрсәтеп азапланунын ни файдасы бар? Арадан Муций Сцеволла чыга: "Сынмаган безнең рухыбыз, - ди ул. һәм шәрә кулын янып торган учакка тыга. - Менә күрегез". Кулы дөрләп янган ут эчендә. Тирә-якка көйгән ис тарала, рим солдаты чыраен да сытмыйча елмаеп тора. "Римлеләрнең кәефләре менә шундый", - дип аңлата ул үзен әсир алган дошманнарына.

4

Вил Мирзаяновның протестын мин юкка гына Муций Сцеволла батырлыгы белән чагыштырмадым. Вилнең протесты аның үзен, гаиләсен ачлык михнәтенә, хәерчелеккә китереп терәп куя. Суд ясауны юри озакка сузалар. Процесс инде өч ел дәвам итә. Вилнең эшкә урнашу, берәр төрле юл белән тамак туйдыру мәсьәләсен хәл итү мөмкинлеге юк. Аның хатынының, балаларының язмышы - Лубянка кулында. Сындырырбыз, ак флаг күтәрергә мәҗбүр итәрбез дип уйлаганнар булса кирәк репрессияне башлаганда. Һәр колониаль режим коллыкка эләккән халыкның бер өлешен сатып алып, аларга бай яшәү шартлары тудырып, шулар ярдәмендә калганнарны изә, җәберли. Мирзаяновны химик кораллар ясый торган хәрби фән институтына эшкә билгеләгәндә без мул түлибез, нәрсә кушсак, шуны эшләр дип уйлаганнардыр. Аның урынында хәрби серне мыштым гына сатарга да булыр иде югыйсә. Зур акчага, күп миллионга. Бүгенге көндә шушы юл белән зур байлыкка ирешүчеләр саны биниһая. Мирзаянов исә, дәүләтнең милитаристик сәясәтен, аның "тынычлык өчен көрәшәбез" дип күз буявын ачыктан-ачык фаш итүне максат итеп куйган. Һәм ул гамәлне пәйгамбәрләр вазыйфасы дәрәҗәсендә башкара алган.

Вилнең "Московские новости" газетасына биргән интервьюсыннан соң башта фашизм тулгагы белән газапланган Русиядә, аннан Аурупа илләрендә, ниһаять АКШта, барлык континентларда Мирзаяновның "әшәкелек империясенә" каршы ялгызы мәйдан тотуын беләләр. Татарстан да битараф калмады. Кыска гына вакыт эчендә шау-гөж килеп куйдылар. Куйдылар һәм тиздән онытта да башладылар шикелле. Бу вакыйга тарихка керәп кала торганнардан. Вилнең бу эше татар халкының сүнмәс, онытылмас горурлыгы булып калачак. Һәм азатлык көрәшендә, мөстәкыйльлек юлында бу үрнәк ифрат кирәк иде. Хакыйкать өчен, ялганга, күз буяуга, өстенә сарык тиресе бөркәнгән ерткычлык сәясәтенә каршы амбразурага ташланган бездә кем бар иде? Хәтерләмим андый шәхес булуын.

5

БМО трибунасыннан халыкара конгрессларда Русия вәкилләре ничәмә тапкыр химик коралларны тыю һәм бетерү турында декларация кабул итүне күтәреп чыктылар. Ниһаять, сугыш шартларында химия белән агулауны кулланмау; химик кораллар ясауны туктату, ясалганнарын юкка чыгару турында декларация кабул ителде. Нәкъ шушы декларациягә таянып, Гыйракның барлык хәрби складларын тикшереп-тентеп йөрделәр. Шул тентүдә Русия вәкиле дә катнашты, чөнки декларациядә бу ил вәкиленең имзасы беренче урынга куелган иде. Имзалар куелган, ратификация уздырылганнан соң декларация законга әверелде. Шундый декларацияне бозу - закон бозуга тиң. Җинаятьне аерым шәхесме, төркемме, тулысынча дәүләтме эшли - хөкемгә тартылырга, җәза алырга тиеш. Гыйракның хәрби объектларын тентеп, тыелган коралларны пыр туздырып йөрү безгә табигый тоелды. Ә инде шул тикшерүне оештырып гамәлгә ашырып йөрүче АКШ һәм Русия вәкилләренең үзләренә барып, шушы илләрдәге химик корал саклана торган складларны тикшерү эшкә ашырып булмаслык катлаулы мәсьәлә.

Мирзаяновның "Московсие новости" газетасы һәм чит ил хәбәрчеләренә биргән интервьюларыннан безгә менә нәрсә мәгълүм булды. Химик коралны көчәйтү, аны һаман яңарту, тагын да куркынычракларын уйлап табу әле һаман дәвам итә икән. Русиянең яшерен хәрби складларында җир шарында яшәүче барлык кешеләрне, шул исәптән, барлык җәнлекләрне, кош-кортларны, бөҗәкләрне агулап үтерергә җитәрлек химик корал - агу тупланган. Мирзаяновның әйтүенә караганда (бу өлкәдә аннан да хәбәрдар башка галим бар микән?), хәзер инде аларны саклау гына да зур куркыныч ясап тора. Шул агуларны әзерләүче заводлар тирәсендә, әзер химик кораллар саклана торган складлар урнашкан төбәкләрдә авыручылар күбәя. Беренче чиратта балалар авырый. Әзер агуларны саклау елдан-ел катлаулана барачак. Химик корал саклаучы складлар урнашкан төбәктә җир тетрәде ди. Фаҗигане күз алдына китерүе дә куркыныч.

Русиянең коралды көчләре серләре турында хәзер инде ачыктан-ачык яза башладылар. Дедовщина, садистлык, тәртипсезлек. Ел саен әллә никадәр солдат һәлак була. Вилнең әйтүенә караганда, дошманны агулап үтерү өчен ясалган корал безнең хәрбиләрнең вәемсызлыгы аркасында, армиядә тәртипсезлек хөкем иткәнлектән, дошманнан бигрәк, Русиянең гөнаһсыз бәндәләрен юк итәргә мөмкин. Вил Мирзаянов шул турыда сөрән салып, хакимият әһелләренә мөрәҗәгать итә. Ә алар исә ишетмәмешкә салышалар.

Галим Мирзаянов шушы көнгә кадәр тупланган барлык химик коралларны юкка чыгару өчен чиктән тыш четерекле гыйльми кулланма уйлап табарга кирәк булачак дигән фикергә килгән һәм шул кулланманы әзерләүне үз өстенә алырга вәгъдә бирә. Билгеле, аның бу изге теләгенә дә колак салырга теләмиләр. Инде менә өченче ел аңа суд белән, төрмәгә утыртү белән яныйлар һәм шушы юл белән куркытып, аны сындырмакчы, баш идертмәкче булалар.

Көрәш дәвам итә. Бер якта - "әшәкелек империясе", аның кораллы көчләре, яңа КГБ берләшүдән туган яшерен оешма, миллионлаган җан ияләрен мизгел эчендә агулап үтерүгә корылган химик корал ясаучылар, икенче якта - безнең милләттәшебез, татар гаиләсендә туып үскән, чын милли зыялылыкта тәрбияләнгән Вил Мирзаянов. Якташыбыздагы ихтыяр көче, рухият егәре, инану шулкадәр көчле, бу титаник көрәштә аның җиңеп чыгуына ышанасым килә. Дөрес, аның үзен юк итә алырлар, ләкин ул башлаган эшне, аның тарихта чиктән тыш сирәк очрый торган батырлыгын берниндә көч, беркем юкка чыгара алмаячак. Татар халкының горурланырга хакы бар. Минемчә, татар галименең кешелек дөньясы иминлеген саклауга керткән өлеше Рудольф Нуриевның дөнья культурасында калдырган эзеннән бер генә мыскалга да ким түгелдер.



6

1993 елда Вил Мирзаяновка Ковалло бүләген тапшырдылар. Бу дөньякүләм бүләк Нобель бүләге шикелле зур байлык та, бездәге Ленин бүләге шикелле өстенлекләр дә бирми. Шуңа карамастан, бәлки Ковалло бүләге бүгенге көндәге иң изге, зур ихтирамга лаеклы бүләктер? Эш менә нәрсәдә. Фән өлкәсендәге ачышларны галимнәр ясый, ә фәнни ачышларга таянып эшләнгән техник нәтиҗәләр, кораллар, машиналар, көнкүреш әсбаплары сәясәтчеләр һәм комсыз монополистлар кулына килеп эләгә. Файдасын алар күрәләр. Атом төшенең серен ачу өлкәсендә галимнәр күпме көч түктеләр. Шушы көчләрнең нәтиҗәсе кешелек дөньясына чиксез зур зыян китерде, чөнки атом төшенең серенә таянып атом бомбасы, радиоактив корал әзерләделәр. Атом бомбасы һәм радиоактив корал сәясәт аша хакимият башына менгән кешеләр кулында. Атом бомбасын шартлату-шартлатмауны шулар хәл итә. Ковалло бүләге нәкъ менә шушы гаделсезлеккә каршы юнәлтелгән. Аны фән өлкәсендә әхлак кануннарын саклап, фәнни ачышларны кешелек дөньясының иминлеге өчен кулланырга өндәүчеләргә бирәләр.

Вакыт үтәр, без аңлый башларбыз. Кешелек дөньясын агулап юкка чыгарудан коткару юлында көрәш башлап җибәрүдән тыш, Вилнең көрәштә кулланган тактикасы да безгә, мөстәкыйльлек юлына баскан татар зыялыларына, үрнәк булырга тиеш. Мирзаянов тоталитар системага, "әшәкелек империясе"нә каршы Махатма Ганди ысулында, аның тактикасы нигезендә көрәшә. Каршылык күрсәтмичә буйсынмау дип атала бу тактика. Каршы як көчле. Аның кулында миллионлаган армия, танклар, самолетлар, атом көче тутырылган ракеталар. Без бары тик бер очракта гына җиңеп чыга алабыз: капма-каршы як оештырган провокациягә бирелмәгән очракта гына.

Махатма Гандиның инглиз колонизаторларына каршы оештырылган көрәшен тикшереп карыйк. Чыннан да бит, ул чакта Һиндстан Англиягә караганда күп мәртәбә көчсез иде. Аларны да нәкъ бүгенге Татарстанны куркыткан шикелле, юкка тырышмагыз, сез барыбер бездән башка мөстәкыйль яши алмыйсыз, бездән аерылсагыз, ачка үлеп бетәчәксез, дип куркытып тордылар. Менә шушы шартларда азатлык хәрәкәтенә юл күрсәтүне үз өстенә алган Махатма Ганди дөрес тактика тапты. Колонизаторларга буйсынмаска, һинд халыкларын талауда катнашмаска һәм шушы эшне гамәлгә ашыруны ничек кенә булса да бәрелешкә, кан коюга әверелдермәскә.

Мин нигә Вил Мирзаяновның әхлак өлкәсендә эшләгән батырлыгы турында сөйләнүдән, гомумән, җәмгыятьтәге әшәкелекләргә каршы көрәш темасына күчтем? Вилнең кешелек дөньясына каршы җинаять эшләүдән баш тартуы - аның шушы эшне оештыручыларны һәм алып баручыларны фаш итүе. Мондый гигант зурлыктагы протест тарихта сирәк очрый торган бөек гыйсъян.

7

Мәкаләмне яза башлау белән Вил Мирзаянов күрсәткән үрнәкне тулы килеш, аңлаешлы итеп укучыга җиткерүнең чиктән тыш катлаулы булуын сизеп тордым. Совет чорындагы татар әдәбияты укучыны Александр Матросов "подвигын" кабатлаган геройларга охшашлы әдәби образлар тудыру белән шөгыльләнде. Шул әдәби геройларның барысын бергә туплап, шулардан уңай сыйфатлы татарның әдәби сурәтен (имиджын) әзерләсәк, смирно басып начальникларнең теләсә нинди боерыкларын үтәргә әзер, кирәк икән - тоталитар хакимият өчен җанын фида итүне үзенең төп бурычы санаган, күндәм, риясыз, шактый куштан, тәлинкә тотарга яратучы бер бәндә килеп чыгар иде. Мирзаянов исә шушы "образцово-показательный" геройның капма-каршысы.

Вил Мирзаяновны кулга алып бераз төрмәдә тоттылар. Әгәр Аурупа һәм Америка галимнәре аны яклап җир шарына яңгырарлык итеп тавыш күтәрмәгән булсалар, аны инде күптән иң каты җәзага тарттырып, зинданга ябып куйган булырлар иде.

8

Борынгы һинд эпосы "Махабхарата"ны укыган кеше хәтерли торгандыр. Анда бүгенге көн өчен чиктән тыш актуаль бер изге канун сурәтләнгән. Сүзгә-сүз рәвешендә язмыйча, истә калганнарны тапшырам. Сугыш шартларында корал куллану турында "Махабхарата"да болай диелгән: җәя һәм укны, сөңгене шушы коралны тота белүче; ватанына тугрылыклы һәр сугышчыга тапшырырга була. Ә менә ерактан яндыра алган көчле утны (греклар кулланган ут турында сүз бара шикелле) бары тик әхлаклы һәм изге кешегә генә тапшырырга ярый. Ә инде кулланганнан соң дошманны гына түгел, шул тирәдәге барлык тереклек дөньясын юк итә торган һәм шушы ут кулланылганнан соң бу җирне мәңгегә яшәү өчен ярамаска әверелдерә торган (атом коралына киная булып яңгырый бу тасвирлау) корал белән бары тик Алла гына эш итәргә тиеш.

Безнең чордан берничә мең ел элек корал куллануның әхлакый кануннары уйлап чыгарылган булган шикелле тоела "Махабхарата"дагы фикерне искә алганда. Бүгенге көндә теләсә нинди авантюрист, күрше илләрне басып алу, буйсындыруны максат итеп куйган кешеләрнең кулына атом коралы, тереклек дөньясын агулап юкка чыгарырга көйләнгән химик коралны тоттыру берниндә җинаять булып тоелмый. Безнең якташыбыз фән докторы Вил Мирзаяновның шушы җинаятькә каршы баш күтәрүе, бәлки, киләчәктә шундый коралларны бетерергә ярдәм итәр.

1993 ел, декабрь.
Переделкино.



АКШ. Американлылар искиткеч аралашучан һәм дустанә халык. Аларда җимерелгән чырайны күрмәссең. Әйтерсең, американлыларның берниндә борчу-хәсрәтләре дә юк. Ләкин бу алай түгел. Борчу-мәшәкать аларда да җитәрлек. Ләкин американлы эчендәгеен беркайчан да тышка чыгармый. (Әле күптән дә түгел татарлар да шундый халык иде бит. Бәлки, без бу сыйфатны әле йөз процент ук югалтып бетермәгәнбездер?)

Рәсемдә: туңдырма сатучының елмаюлы йөзе.




Озак еллар буе уздырылып килүче халыкара конкурска ярты миллионнан артык фоторәсем килгән. Аны атаклы "Кодак"компаниясе уздыра.

Рәсемдә: җиңүче дип табылган фоторәсемнәрнең берсе ("Пиза манарасына охшаш сарай").



Япон модельеры Иссия Мияке менә бу модельне иҗат иткәндә табигатькә якынрак булуны максат иткәндер, мөгаен.



Якындагы өч елда автомобиль базарында "Мерседес-Бенц" концернының мини-мерседесы пәйда булачак. Мини-мерседесның озынлыгы бары 3,35 м.

ИТАР-ТАСС фотолары.

ТВ АТНАЛЫК ПРОГРАММА

ДҮШӘМБЕ

31 гыйнвар

ТАТАРСТАН

7.00 Чулпан.
18.00 Мультфильмнар.
18.50 Татарча сөйләшәбез.
19.00 Татарстан.
19.35 Республика: сәяси көндәлек.
20.05 Әлли-бәлли-бәү.
20.15 Шигърият.
20.30 Чишмәләр җыры.
22.55 Гиннесс-шоу.

ЭФИР

7.00 Мультфильмнар.
7.30 Анонслар.
7.45 Киноменю.
8.10, 15.00 Супер чэннел.
12.00 Төркия ТВ.
17.00 Мультфильмнар.
17.25 Муз.фильм.
18.30 Муз.программа.
19.45, 22.50 Шәһәр.
20.00 Телетекст.
20.15 Камиллекнең үзе.
20.35 Видеомода.
21.00 Комедия. "Бриллиант кул".
22.45 Нәрсә? Кайда? Күпме?

ОСТАНКИНО

6.00, 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00 Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика.
6.30 Иртә.
8.45 Мультфильм.
9.20 Кара, тыңла...
9.40, 19.10 "Тормыш вакыйлары".
10.10 Тема.
10.55 Э.Грач уйный.
11.20, 17.10 Йолдыз сәгате.
12.20, 18.25 Гол.
15.25 Эшкуар.
16.10 Компас-әкият.
17.50 Технодром.
18.55 Документлар һәм язмышлар.
19.40 Миниатюра.
19.55 "Светлана - Иосиф кызы". 2 кисәк.
20.40 Тыныч йокы, нәниләр.
21.45 Галантлы гасыр мәхәббәте.
22.45 К.Райкин турында.
23.35 Пресс-клуб.

РОССИЯ

7.00, 14.00, 20.00, 23.20 Хәбәрләр.
7.20 Таләп ителә...
7.30 730 формуласы.
8.20 Эшлекле кешеләр вакыты.
8.50 Мультфильм.
9.00 Дөнья яңалыклары.
9.30 Утә яшерен.
10.20 Концерт.
11.30, 17.15 Яңа линия.
12.00 "Павел Корчагин". Н.ф.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.25 "Минем диңгезче". Н.ф.
15.40 Параллельләр.
15.55 Телегазета.
16.00 Россиядә бизнес.
16.30 Там-там яңалыклары.
16.45 Сабый теле белән.
17.50 Коткару 911.
18.45 Рус визасы.
19.15 Абракадабра.
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.25 Нечкәлекләр.
20.40 Дүшәмбе детективы.
21.40 Хроно.
22.15 Бизәмичә.
23.45 Йолдызлар сөйли.
23.50 Спорт карусельe.

ПЕТЕРБУРГ

8.05 "Таң алдыннан".
9.00 "Кино йорты".
10.00 "Атаклы үрдәк бәбкәсе Тим".
11.10 "Паутиныч яшәгән җирдә".
11.30 Ашыгыч ярдәм.
12.00 Теледоктор.
12.15 Мультфильм.
13.30 "Балтия күге". 1 серия.
14.55 Фильм-концерт.
21.35 Телемагазин.
21.45 Комедия. "Шушы самолет артыннан барыгыз".
23.10 "Тәкъдиргә язган мәхәббәт". Н.ф.
23.35 Сезнең стиль.
0.05 Ля сет.

СИШӘМБЕ

1 февраль

ТАТАРСТАН

7.00 Чулпан.
18.10 Компьютер информациясе.
18.20 Экран - балаларга.
18.50 Татарча сөйләшәбез.
19.00 Татарстан.
19.35 Сәламәтлек.
20.10 Әлли-бәлли-бәү.
20.25 Рөстәм Үтейнең иҗат кичәсе.

ЭФИР

7.00, 17.00 Мультфильмнар.
7.30 Шәһәр.
8.00, 15.00, 17.50 Супер чэннел.
10.00 "Бриллиант кул".
12.40 Төркия ТВ.
17.25 Европа калейдоскобы.
19.40 Үз авызыннан.
20.00 Телетекст.
20.30 "Сугу ноктасы". Н.ф.
22.10 Нәрсә? Кайда? Күпме?

ОСТАНКИНО

6.00, 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00 Яңалыклар.
6.30 Иртә.
8.45 Мультфильм.
9.20 Шаян ноталар.
9.40, 19.05 "Мария".
10.30 Кеше һәм закон.
11.00 Концерт.
11.50 Пресс-экспресс.
12.20 "Салам эшләпә". Н.ф.
14.30 Садовое кольцо сараенда.
15.25 Эшлекле хәбәрче.
15.40 Эшлекле тормыш хроникасы.
16.20 "Минем гаилә һәм башка хайваннар". 7 серия.
16.55 "Тамашачыга әйләнеп кайту".
17.10 Безнең музыкаль клуб.
17.50 Милекче әлифбасы.
18.25 Арткы якта.
18.50 Документлар һәм язмышлар.
19.55 Тема.
20.40 Тыныч йокы, нәниләр.
21.45 Лидер.
22.30 Беренче булып.
22.45 Олимпиячеләр балы.

РОССИЯ

7.00, 14.00, 20.00, 23.20 Хәбәрләр.
7.20 Таләп ителә...
7.30 730 формуласы.
8.20 Эшлекле кешеләр вакыты.
8.50 Мультфильм.
9.00 Дөнья яңалыклары.
9.30 "Сары су асты көймәсе клубы".
12.00 "Дустым Иван Лапшин". Н.ф.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.25 "Тормыш сабагы". Н.ф.
16.15 Концерт.
16.30 Там-там яңалыклары.
17.15 Яңа линия.
18.00 Чайковский романслары.
18.45 Гадинең гадие.
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.25 Нечкәлекләр.
20.40 "Санта Барбара".
22.15 Тын йорт.
23.45 Йолдызлар сөйли.
23.55 Сукояр авазы. "Кешелек, кая барасың?"

ПЕТЕРБУРГ

8.05 "Адәм һәм Хава".
8.35 Яңа заманалар.
9.10 Хронограф.
10.40 Әкият арты әкият.
11.15 "Алтын ачкыч".
12.00 Док.фильм.
12.40 Камертон.
13.30 "Балтия күге". 2 серия.
14.50 Фильм-концерт.
15.40 Комедия. "Ак сәяк".
21.45 "Таң алдыннан".
22.35 "Блеф-клуб".
23.15 Римский-Корсаковның тууына 150 ел.
23.35 Сезнең стиль.

ЧӘРШӘМБЕ

2 февраль

ТАТАРСТАН

7.00 Чулпан.
18.05 Музыка дөньясына сәяхәт.
18.25 Хуҗалар.
18.50 Татарча сөйләшәбез.
19.00 Татарстан.
19.35 Профсоюзлар: законлылыкны тормышка ашыру.
20.05 Әлли-бәлли-бәү.
20.15 Ф.Яруллин, "Шүрәле" генә түгел...
21.00 Борынгы татар моңнары.

ЭФИР

7.00, 17.00 Мульфильмнар.
8.05 Муз.программа.
10.00 "Харлей" хикәяте". Н.ф.
11.35 Төркия ТВ.
15.00 Супер чэннел.
17.25 Европа калейдоскобы.
17.50 Смоки Робинсон концерты. Муз.фильм.
18.40 Муз.программа.
19.45, 22.40 Шәһәр.
20.00 Телетекст.
20.50 "Аддамслар гаиләсе". Н.ф.
22.35 Нәрсә? Кайда? Күпме?

ОСТАНКИНО

6.00, 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00 Яңалыклар.
6.30 Иртә.
9.40 "Итекле мәче". Фильм-спектакль.
10.30 Сәяхәтчеләр клубы.
11.50 Пресс-экспресс.
12.20 "Чиста инглизчә үтерү". 1 серия.
13.40 Урыс кунаклары.
15.25 Эшкуар.
16.20 "Минем гаилә һәм башка хайваннар". 8 серия.
17.20 "Оча торган йорт".
17.50 Технодром.
18.25 "Мир" ТРКсы.
18.55 Футбол.
21.45 Бәхетле очрак.
22.50 "Сережа". Н.ф.

РОССИЯ

7.76 14.00, 20.00, 23.20 Хәбәрләр.
7.20 Таләп ителә.
8.20 Эшлекле кешеләр вакыты.
8.00, 13.25, 15.50 Мультфильмнар.
9.00 Дөнья яңалыклары.
10.00 Бизәмичә.
10.55 В.Чкалов турында фильм.
12.00, 17.15 Яңа линия.
12.30 "Балакәч". Н.ф.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.25 "Озын толымлы гүзәл Варвара". Н.ф.
16.55 Телегазета.
16.30 Там-там яңалыклары.
18.00 Дөнья һәм сугыш.
18.45 Док.фильм.
19.35 Криминаль хәбәрләр.
22.25 Нечкәлекләр.
20.35 "Санта Барбара".
21.25 Л-клуб.
22.15 Көтеп тору залы.
23.05 Өлкәннәр өчен мультфильм.
23.45 Йолдызлар сөйли.
23.55 "Ностальжи".

ПЕТЕРБУРГ

7.30, 11.15 Мультфильм.
8.05 "Таң алдыннан".
9.00 Цхинвал. Җырлар тукталган вакыт.
10.40 "Паутиныч яшәгән җирдә".
10.55 "Өч тәгәрмәч, Фолиант һәм башкалар..."
12.00 Фильм-концерт.
12.40 Көмеш җеп.
13.55 "Актриса". Н.ф.
15.40 Безнең кино.
17.10 "Табылдыкдар бюросы". Мультфильм.
21.45 Ж.Сименон. "Ул искә алу көнендә килде".

ПӘНҖЕШӘМБЕ

3 февраль

ТАТАРСТАН

7.00 Чулпан.
18.00 Компьютер информациясе.
18.05 Спорт, музыка, көлү...
18.50 Татарча сөйләшәбез.
19.00 Татарстан.
19.35 ГАИ-информ.
19.40 Депутат каналы.
20.15 Әлли-бәлли-бәү.
20.25 Төркия ТВ.

ЭФИР

7.00, 10.00, 17.00 Мультфильмнар.
8.00, 15.00 Супер чэннел.
10.55 Төркия ТВ.
17.25 "Су төбендәге аквалanглар". Н.ф.
18.45, 20.15 Муз.программа.
19.40 Дөнья бүген.
20.00 Телетекст.
20.35 "Рим". Н.фильм. (Ф.Феллини фильмы).
22.45 Нәрсә? Кайда? Күпме?

ОСТАНКИНО

6.00, 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00 Яңалыклар.
6.30 Иртә.
8.45, 9.20 Мультфильмнар.
9.40, 19.05 "Мария".
10.30 Хайваннар дөньясында.
11.10, 17.20 ...уналтыга кадәр һәм өлкәннәрләр.
11.50 Пресс-экспресс.
12.20 "Чиста инглизчә үтерү". 2 серия.
13.40 Мультфильм.
14.00 Футбол.
15.25 Эшкуар.
16.20 "Минем гаилә һәм башка хайваннар". 9 серия.
16.55 Музограф.
18.25 Лабиринт.
18.50 Документлар һәм язмышлар.
19.55 Т.Петрова җырлый.
20.10 "Тартма кешесе".
21.45 "Миллион" лоттосы.
22.15 "Твин Пикс". 26 серия.
0.30 Күңел ачу тамашасы.

РОССИЯ

7.00, 14.00, 20.00, 23.20 Хәбәрләр.
7.20 Таләп ителә...
8.00 Сигнал.
9.00 Дөнья яңалыклары.
9.30, 16.15 Мультфильмнар.
9.40 "Кешелек, кая барасың?"
10.40 К-2.
11.30, 17.10 Яңа линия.
12.10, 20.40 "Санта Барбара".
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.25 "Бу хәл Пеньковта булды". Н.ф.
16.00 Концерт.
16.25 Там-там яңалыклары.
16.40 "Рост" студиясе.
17.55 Глобус.
18.25 Карьера әлифбасы.
19.25 Мин - лидер.
20.25 Нечкәлекләр.
21.30 "Д.Покровский инфы.
22.20 Ватаным.
23.45 Йолдызлар сөйли.
23.55 Криминаль хәбәрләр.

ПЕТЕРБУРГ

7.30, 11.10 Мультфильмнар.
9.10 Европа калейдоскобы.
9.40 Яңа Петербург.
10.40 Әкият арты әкият.
11.30 Ашыгыч ярдәм.
12.00 "Җиде фил".
12.40 Фильм-концерт.
13.05 "Шушы самолет артыннан барыгыз." Н.ф.
14.30 "Абага чәчәге". Концерт.
15.40 Тарихи альманах.
16.25 "Иң төп номер". Н.ф.
21.45 "Таң алдыннан".
22.35 Фильм-концерт.

ҖОМГА

4 февраль

ТАТАРСТАН

7.00 Чулпан.
18.00 "Алтын чеби".
18.50 Татарча сөйләшәбез.
19.00 Татарстан.
19.35 Видеоспорт.
19.45 Әлли-бәлли-бәү.
20.00 Җомга көн кич белән.
21.10 Җыр-бию ансамбле концерты.

ЭФИР

7.00, 17.00 Мультфильмнар.
10.00 "Су төбендәге аквалanглар". Н.ф.
11.20 Төркия ТВ.
15.00 Супер чэннел.
17.25 Европа калейдоскобы.
17.50 "Леди Аждаһа". Н.ф.
19.30 Муз.программа.
19.45, 22.00 Шәһәр.
20.00 Телетекст.
20.15 "Шәүлә аулаучы". Н.ф.
21.55 Нәрсә? Кайда? Күпме?

ОСТАНКИНО

6.00, 9.00, 15.00, 18.00, 21.00 Яңалыклар.
6.30 Иртә.
8.45, 10.35, 16.10 Мультфильм.
9.20, 16.20 "Сагышлы быргы". Н.ф.
16.50 "Тургай җыры".
11.50 Пресс-экспресс.
12.20 "Портрет". Спектакль.
13.55 Анда, болытлар артында...
14.15 Театр романслары.
15.25 Эшлекле хроника.
15.55 Бизнес-класс.
17.30 Шри-Ланка ритмнары.
17.45 Милекче әлифбасы.
17.55 Футбол.
19.55 Могҗизалар кыры.
21.45 "Твин Пикс". 27 серия.
22.40 Атна кешесе.
22.55 "Югалганны эзләп".
23.35 Телескоп.
0.15 "Музобоз".

РОССИЯ

7.00, 14.00, 20.00, 23.20 Хәбәрләр.
7.30 Таләп ителә...
8.20 Эшлекле кешеләр вакыты.
9.00 Дөнья яңалыклары.
10.15 Көтеп тору залы.
11.05 Безнең бакча.
11.35, 17.05 Яңа линия.
12.05 "Санта Барбара".
15.55 Ак карга.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.25 "Тотылмаслар". Спектакль.
15.35 Корьән буенча яшәүчеләр.
15.50 Мультфильм.
16.05 Россиядә бизнес.
16.35 Там-там яңалыклары.
17.55 "Ак аю эзеннән". 2 серия.
16.45 Шәрман-шоу.
20.25 Нечкәлекләр.
20.40 "Террор сәяхәте". 2 серия.
22.15 "Беркем дә онытылмый".
22.25 К-2.
23.45 Йолдызлар сөйли.

ПЕТЕРБУРГ

7.30, 11.00 Мультфильмнар.
8.05 "Таң алдыннан".
9.00 Кичке яңгырау.
10.40 Балаларга җәнлекләр турында.
11.30 Ашыгыч ярдәм.
12.00 Фильм-концерт.
12.40 Россиянең бер почмагы.
13.25 "Ленинның гәүдәсе". Док.фильм.
14.15 Бал биюләре чемпионаты.
16.10 "Мин сине беркайчан да онытмам". Н.ф.
21.45 "Хронограф".
23.35 Сезнең стиль.
0.05 "Котны алучы". Н.ф.

ШИМБӘ

5 февраль

ТАТАРСТАН

7.00 Чулпан.
18.25 "Без уйныйбыз".
18.40 Мультфильм.
19.00 Татарстан.
19.35 "2000 нче елдан соң". 5 серия.
20.25 Әлли-бәлли-бәү.
20.35 Шагыйрь Р.Фәйзуллин.

ЭФИР

7.00, 17.00, 17.25 Мультфильмнар.
7.30 Шәһәр.
8.00 Грация.
8.25 Супер чэннел.
10.00 "Леди Аждаһа". Н.ф.
11.40, 18.20 Муз.программа.
19.30 Кичке Казан.
20.15 Фантом.
21.00 "Ваз кичүче".
23.00 Нәрсә? Кайда? Күпме?
23.05 "Динозаврлар утравы". Н.ф.

ОСТАНКИНО

7.00, 15.00, 21.00 Яңалыклар.
7.35 Шимбә иртәсе.
8.10 Азартлы уеннар.
8.40 Алла ярдәм бирсен.
9.00 Марафон-15.
9.30 "Мир" ТРКсы.
10.55 Иртәнге почта.
11.25 А.Макаревич өйрәтә.
11.40 Китап сарае.
12.20 Соло.
13.20 Үзеңә-үзең ярдәм ит.
14.00 Җиңел атлетика.
15.25 "Пеппи Озыноек".
15.55 Киләчәк телефоны.
16.25 Туплы хоккей.
17.15 "Мария Каллас".
18.00 Эрмитаж. 4 фильм.
18.30 Атна кайтавазы.
19.00 Брейн-ринг.
19.50 "Иң шәп пар". 2 серия.
21.45 "Диңгез сөйләр..." 1 серия.
22.40 Музыкаль ишегалды.
23.55 "Шерлок Холмс". 1 серия.

РОССИЯ

9.00 Ретро-шлягер.
9.30 Билгесез галәм.
10.00 "Рост" студиясе.
10.30 Илгизәр.
11.15 "45" программасы.
12.00 "Үлеләр утравы".
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр.
14.20 Док.фильм.
14.30 Юристлар конкурсы.
16.00 Америка йолдызлары.
16.45 Футбол чикләрне белми.
17.40 Шотландия телевидениесе киче.
17.45 "Сильвер". Н.ф.
18.15 "Аларның музыкасы булыр".
19.15 Сабый теле белән.
20.25 "Бәхетсез мирас". Н.ф.
22.00 "Коннери". Док.фильм.
23.00 Репортер.
23.45 Йолдызлар сөйли.
23.55 "Эфирда биш ел".
0.55 "Син бирә алган нәрсә". Н.ф.

ПЕТЕРБУРГ

8.20 "Котны алучы". Н.ф.
11.30 Ашыгыч ярдәм.
12.00 Сорәүләр буенча концерт.
12.30 Теледоктор.
12.45 "Яшенле яңгыр". Н.ф.
14.25 Көмеш җеп.
15.00 Бүген һәм көн саен.
15.20 Чуар эт.
15.40 Балаларга җәнлекләр турында.
16.00 Мультфильм.
16.20 "Икенче класста икенче елын утыручы Иван Семенов тормышыннан өч көн ярым". Н.ф.
21.40 "Таң алдыннан".

ЯКШӘМБЕ

6 февраль

ТАТАРСТАН

7.00 Чулпан.
18.05 Мультфильм.
18.15 Һинд киносын яратучыларга.
19.10 Атналык күзәтү.
19.40 Әлли-бәлли-бәү.
19.50 "Җомга көн кич белән". Телеспектакль.
21.05 Венера Ганиева җырлый.

ЭФИР

9.00 Грация.
9.25 "Саффи". Мультфильм.
12.00 Камиллекнең үзе.
12.25 Видеомода.
12.45, 20.50 Муз.программа.
13.00 Кичке Казан.
13.45 Фантом.
14.30 Мультфильмнар.
14.55 Супер чэннел.
19.30 Анонслар.
19.45 Киноменю.
20.10 Сәүдә карусельe.
20.45 Нәрсә? Кайда? Күпме?
21.00 Нәтиҗәләр.
22.00 "Минем кыз артыннан кем күзәтә". Н.ф.

ОСТАНКИНО

7.00, 15.00, 18.00 Яңалыклар.
7.30 Телесеренада.
8.50 Рухның кәч сәгате.
9.00 Паузасыз.
9.30 Иртән иртүк.
10.00 Полигон.
10.30 Спортлото.
10.45 Бар да өйдә чакта.
11.15 Иртәнге йолдыз.
12.05 Яшь буын.
12.45 "Пи" билгесе астында.
13.30 Пров нция.
14.00 "Пиф һәм Геркулес".
14.10 Су асты одиссеясы.
15.20 "Мир" ТРКсы.
16.00 Сәяхәтчеләр клубы.
16.50 Өрәк аулаучылар.
17.40 Панорама.
18.10 Телелоция.
18.35 Россия табышлары.
20.05 КВН-94.
22.00 Якшәмбе.
22.45 Спорт уикэнды.
23.00 Променад концерт.
23.50 Автошоу.
0.10 "Зур сәйран".

РОССИЯ


9.00 Хәерле иртә, Европа.
9.30 Зур хоккей.
10.00 "Рост" студиясе.
10.30 Уен дәмасы.
11.00 Армия турында.
11.30 К.Мажейка репортажлары.
12.00 "Яфрак коелу". Н.ф.
14.00, 20.00, 23.20 Хәбәрләр.
14.20 Юнып ташлап булмый...
14.35 Алты сутый.
14.55 Пушкин һәм рус мәдәнияты язмышы.
15.25 NBAның иң шәп уеннары.
16.20 Тапшырулар тартмасы.
16.35 Хайваннар дөньясында.
17.35 Февраль киносы.
17.55 Мультфильм.
18.45 "Шпионаж".
19.15 "Ак-кара рәсемле кино өчен җиде пьеса". Н.ф.
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.25 "Ай фаворитлары". Н.ф.
22.45 Ксюша янында.


ПЕТЕРБУРГ

8.00 Шифалы сүз.
8.30 "Таң алдыннан".
9.20 Петербург ангажементы.
10.10 Экспресс-кино.
10.25, 16.20 Мультфильмнар.
10.55 Яңа заманалар.
11.30 Ашыгыч ярдәм.
12.00 Якшәмбе лабиринты.
14.05 "Мәче йорты". Спектакль.
15.30 Телеуен.
16.10 Алтын ачкыч.
22.10 "Хатын-кызлар тегүчесе". Н.ф.

Ә хәзер яхшы хәбәр...









- *Бәлки, сезне аңлаучы юктыр, алга таба ничек яшәргә дип, сез нишләргә белмичә югалып калгансыздыр? Сезне ялгызлык һәм хәл ителмәгән проблемалар газаплыйдыр?*
- *Бәлки, сезнең интим тормышта проблемалар килеп тугандыр, яки сез венерик авыру йогудан куркасыздыр һәм тикшеренеп карарга телисездер?*
- *Сез, бәлки, үз җенесегездәге кешегә тартыласыздыр?*
- *Сез теләсә кайсы вакытта аноним рәвештә безгә шалтырата аласыз.*
- *Ышаныч телефоны: 38-40-20.*
- *Психологик ярдәм бушлай күрсәтелә. Дүшәмбе, сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга көннәрдә кичке 6 дан иртәнге 8 гә кадәр, чәршәмбе көнне 18-21 сәгатькәчә, шимбә көнне 8 дән 15 сәгатькә кадәр шалтырата аласыз.*
- *Сезнең безгә шалтыратуыгыз наркомания, токсикомания, алкоголизмнан котылу юлында беренче адым булуы мөмкин!*

Җенси азатлык һәм СПИД

СПИД - кешелек тарихына йогынты ясаучы беренче генә эпидемия түгел: кызамык, чәчәк авыруы, чума һәм полиомиелит - болар барысы да үз чорларында эз калдырган авырулар.

Әмма СПИДның йогынтысы заманга карата иблисләрчә булды, ул СПИД өчен тукландыргыч җирлек булган илләрнең бөтен каршылыкларын ачып салды.

60 нчы еллар тирәсендә Көнбатыш Европа илләрендә һәм Америкада ике җенес арасындагы мөнәсәбәтләрнең тамырдан үзгәрүен сексуаль революция дип атыйлар. Газета киосклары витриналары ирләр һәм хатын-кызларның "гүзәллеген" күрсәтүче рәсемнәр белән тула. Секс күзгә күренеп яшәрә - 13-15 яшьлек мәктәп балалары гыйффәтлекләрен югалта башлый.

Балага узуга комачаулый торган төрле таблеткаларның килеп чыгуы хатын-кызларның да секска мөнәсәбәтен җиңеләйтә. Фахешлекнең төрле төре чәчәк ата башлый.

Аерылышуларга, өйләнешкәнгә кадәр җенси мөнәсәбәтләргә керүгә караш үзгәрә. Хатын-кыз эмансипациясе хатыннарны бу өлкәдә дә ирләр белән бертигез хокуклы дип белдерә.

АКШ һәм Көнбатыш Европадагы сексуаль революция төрле венерик авыруларның артуы белән бергә бара. Моңа наркомания, гомосексуализм һәм секс-туризм да үз өлешләрен кертә.

70 нче еллар азагында АКШта 5 млн. гомосексуалист исәпләнә. Төрле яшьтәге бу кешеләр яңа сексуаль кичерешләр эзләп Африка илләренә кадәр барып җитәләр. Күп илләрдә җәмәгатьчелек гомосексуализмга каршы, ул илләрдәге законнар буенча да гомосексуалистлар хөкемгә тартылырга тиеш. Шушы көнгә кадәр бу сексуаль азчылык дигән төркем үзенең җенси азатлыгы, димәк, дөнья буйлап тагы да киңрәк таралу өчен көрәш алып бара.

Чирләр белән көрәш үзәге (АКШ) теркәлгән мәгълүматларның берсеннән күренгәнчә, Лос-Анжелес шәһәрендә яшь кенә 5 гомосексуалист кинәт кенә пневмониянең бик сирәк очрый торган төре белән авырый башлый. Аларның икесе үлә. Күпмедер вакыттан бу үзәк яңа мәгълүматлар туплый: Лос-Анжелеста тагын 4 кеше, Сан-Францискода - 6, Нью-Йоркта - 20 кеше шушы сирәк төр пневмония белән авырый башлаган. Барысының да иммун системасы серле рәвештә яраксыз хәлгә килгән. Җәйгә бу сан инде 116 га җиткән.

МЖК Мосстрой уртак предприятиесе исеменнән аның директоры МИФТАХОВ ИРЕК ИЛДАРОВИЧ

СПИДка каршы көрәш Үзәгенә бу чирне кисәтү буенча массакүләм чаралар уздыру өчен спонсорлык ярдәме күрсәтте.

КОТЛЫЙБЫЗ!



Газетада котлау турында белдерү бастыру өчен редакция счетына 10.000 сум акча күчерергә һәм акча күчерү турындагы квитанция белән котлау текстын редакция адресына җибәрергә кирәк. Хатларыгызны бер ай алдан җибәрүегезне сорыйбыз.

Апас районының Түбән Биябашы авылында яшәүче әтиебез белән әниебез 40 ел тату-тигез гомер кичереп, өч ул һәм ике кыз тәрбияләп үстерделәр. Әниебез Мифтахова Римә Хәлилрахман кызына 28 гыйнварда 60 яшь тулды. Әтиебез Мифтахов Нуретдин Зәйнетдин улына 17 февральдә 65 яшь тула. Әтиебез белән әниебезне чын күңелдән туган көннәре белән тәбрик итәбез, аларга саулык, сәламәтлек, озын гомер, бәхет телибез.

Уллары, кызлары, киявләре, оныклары.

* * *

Саба районы, Явлаштау авылында яшәүче әниебез Гыйльметдинова Мәхтүмәнең 2 февральдә туган көне. Сөекле әниебез! Сине чын күңелдән туган көнең белән тәбрикләбез. Сиңа исәнлек-саулык, бәхетле мул тормыш, балаларыңның игелеген күреп, күңел тынычлыгы белән яшәвеңне телибез.

Сиңа иң изге теләкләр белән: кызларың, киявләрең, улың, киленең һәм 13 оныгың исеменнән Тайфә кызың.

* * *

Биектау районының Кызылкүл авылында яшәүче, җир йөзендә иң кадерле кешебез - әниебез Фердинан Вәлиевага 6 февральдә 60 яшь тула. Бу олы бәйрәме белән әниебезне чын күңелдән котлыйбыз. Дөньяда әниләргә әйтелгән иң изге сүзләргә кушылып, аңа чын йөрәктән нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы, әтиебез белән бергә кайгы-хәсрәтсез тигез - озын гомер телибез.

Иң изге теләкләр белән, 5 балаң, 3 киленең, 2 киявең, 12 оныгың һәм әтиебез исеменнән - кызың Нурия.



Укучыларыбыз игътибарына!

Газетабызда шәхси белдерүләр бушлай бастырылуы турында кабат исегезгә төшерәбез. Сез әйбер сату яки алу, фатир алмаштыру, әйберләр югалту яки табу, берәр кешегә булган теләк яки мөрәҗәгатегезне, кыскасы, теләсә нинди эчтәлектәге шәхси белдерүегезне хат белән яки редакциянең реклама бүлегенә шалтыратып хәбәр итә аласыз.

Инвалид коляскасы сатам.
Адрес: 422400, Г.Буинск, ул.Шафранова, д.20, кв.20, Рахманова М.

* * *

34 кв.м. мәйданлы Адоратский урамындагы 2 бүлмәле фатирны (Ленинград проекты, 3 этаж, телефон кереpгә тора) берәр бүлмәле ике фатирга алмаштырам.
Телефон: 42-27-84 (эшнеке). Сабирҗанова Нурания.

* * *

ДТ-74 тракторын мини тракторга алмаштырам.
Адрес: Әгерҗе районы, Кичке-Таң авылы, Нуриманов.

* * *

1 ноября 1993 года в пригородном поезде Казань - Буа нашли бумажную коробку с вещами.
Адрес: Буинский район, дер.Мало-Буинка. Фаткуллина Фарида.



Бер урыс - икенчесенә:

- Карале, күрше, синең теге чучкаңның арт аягы нишләгән? Әллә агачтан инде?
- Бер койка өчен генә дуңгыз кадәр дуңгыз суйымыйм дидем...

* * *

Хатын-кыз - бүгенге ирләр турында: "Өстеңә салсаң - йоклый, астыңа тыксаң - тыны бетә, кырыңа яткырсаң - телевизор карый, тәпиеңә бастырып куйсаң - чыгып сыза!"

* * *

Әнисе ике игезәк алып кайткач, кечкенә Вәли - әтисенә:

- Әти, боларның барысы да бездә каламы, әллә арадан берсен сайлап алырга дип җибәргәннәрме?

* * *

Кибет киштәсендә ике тавык түшкәсе ята. Чит илдән китерелгән түшкә мактана:

- Кара, мин нинди матур: үзем алсу, үзем симез, үзем затлы пакет эчендә. Ә син зәңгәрләнеп катkансың, хәтта җоныңны да йолкып бетермәгәннәр...
- Аның каравы, мин үз үлемем белән үлдем.

* * *

Балалар бакчасында ике малай сөйләшә:

- Сиңа ничә яшь?
- Дүрт. Ә сиңа?
- Белмим.
- Кызлар белән кызыксынасыңмы?
- Юк.
- Димәк, өч яшь.

* * *

Хайваннарның өстенлеген раслаучы бер мисал. Ат чабышында утыз ат катнашса, аны карарга илле мең кеше җыела. Ә менә утыз кешене чабышка чыгарсаң, аларны карарга бер ат та килмәячәк.

* * *

Хатыны - иренә:

- Сизәсеңме, яхшы билгеләр өчен акча түли башлагач, бала ничек алдырып китте?
- Сизәм... Тик, сүз беркетеп, укытучысына да өлеш чыгармый микән, дип шикләнеп торам әле.

* * *

Җәнлекләр арасында бәхәс чыккан: аларның кайсысы иң матуры, ә кайсысы иң акыллысы? Бәхәсләшә торгач, бер фикергә килгәннәр: матурлар - сулга, ә акыллылар уңга чыксын. Бөтенесе бүленешеп беткән, уртада маймыл гына басып калган.

- Ә син нишләп торасың? - дип кычкыралар икән моңа җәнлекләр.
- Нишлим соң, икегә аерылыйммени?

ТЯ

Баш мөхәррир
Исмәгыйль ШӘРӘФИЕВ

ЯЗЫГЫЗ:
420066, Казан, Декабристлар урамы,2.
"Татарстан яшьләре"

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
53-07-52 - баш мөхәррир урынбасары
53-07-54 - җаваплы сәркатип, реклама
53-07-58 - хатлар бүлеге
53-07-54 - тәрҗемә
53-07-56 - сәясәт, мәдәният-сәнгать
53-07-52 - авыл хуҗалыгы, экология
53-07-50 - рәссам, компьютер операторлары.

"Татарстан яшьләре"н гамәлгә куючылар - Татарстан Республикасының Яшьләр оешмалары советы, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы, редакциянең хезмәт коллективы.

Газета Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 268-нче номерлы таныклык белән теркәлде.

"Т.Я" сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга

Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

Реклама һәм белдерүләрдәге мәгълуматларның дөреслеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.

Редакциянең исәп-хисап счеты:
Р/с 700161998/700751 ВКАБ РКЦ ГЦБ г.Казани, МФО 265005
Индекс - 54121
Тираж - 200000

Татарстан газета-журналлар басмаханәсе.

Газета басылуга кул кую график буенча 18 сәгатьтә. Бу санга 15 сәгатьтә кул куелды.

Заказ 6201